# Язучы якташым белән туган ягымны данлыйм!

*Иске Богады авылы китапханәсе.*

www.tvoyrebenok.ru

# Рушания Байтимерова

## Гомер көземдә - язым.






## *Гомер көзе матур үтсен*


Чигәләрдә көмеш төсләр
Өлкәнлек билгеләре.
Зирәк акыл, сабырлык һәм
Күркәмлек өлгеләре.

Ил тарихы өлкәннәрдә,
Ил белән үткән юллар.
Ирешелгән уңышлар һәм
Сынаулар тулы еллар.

Тирән рәхмәт, олы хөрмәт
Хисләре сезнең өчен.
Боекмасын күңелегез-
Кирәк Сез безнең өчен.
Терәк Сез безнең өчен.

Яшәгез гел шатлык белән,
Бирешми сагыш – моңга.
Гомер көзе матур узсын,
Күмелсен якты нурга.

**Үз ягымның кешеләрен сөям,**
**Шат елмаеп үтә һәр таныш.**
**Әллә инде сирәк кайткангамы,**
**Бик сагынам Сине, Актаныш!**




### Богадым - туган авылым

Яшел хәтфә җәйгән үзәннәрең
Чишмәләрең белән гүзәлсең.
Богадыма юллар өзелә калса,
Сагышларга ничек түзәрсең?

Кушымта:

Авылым, авылым
Туган җирем.
Иркәли, иркәли
Назлы җилең.

Куенында тибрәткәнсең назлап,
Гомер бишеккәем, Богадым.
Бурычлымын сиңа мәңгелеккә,
Тормышка мин синнән юл алдым.

Кушымта.

Онытылмас якты сагыш булып
Йөрәкләрдә мәңге калырсың.
Күңелләрдә гел янәшә булып
Гомер буе озатып барырсың.

Кушымта.

### Үз ягыма

Үз ягыма кайтсам җанга рәхәт,
Бөтен нәрсә якын миңа, үз.
Йөрәкләрне эретергә җитә
Үзебезчә әйткән һәрбер сүз.

Юллары да йомшак тирбәтәләр,
Сикәлтәләр бер дә сизелми.
Үз ягымның һәрбер нәни ташы
Мин кайтканны гүя сиземли.

Туган якның җылы җилләрендә
Назланасы килә шул чакта.
Бар дөньясын кочып сөяр идем,
Сыйса әгәр минем кочакка.

Үз ягымның кешеләрен сөям,
Шат елмаеп үтә һәр таныш.
Әллә инде сирәк кайткангамы,
Бик сагынам сине, Актаныш.

### Туган җирем

Кузем алмыйм иген кырларыннан,
Башак шавы назлый колакны.
Үзем белән алып китәр идем
Һәр агачны, һәрбер куакны.

Балачагым үткән яланнардан
Әйләнәм мин кат-кат сагынып.
Яр буенда үскән тирәкләргә
Әй елыйсы килә сарылып.



**Без бәләкәй чакларда**
*июнь, 1963 ел*



**Әткәй, әнкәй – минем кадерлеләрем**
2005 ел

**Шигырьләрем аша таныштык, Инде якыннан да танышыйк.**



***Нәсел җебе дәвам итә...***
*28 июль, 2007 ел.*


Бездә көтү бик тә иртә чыга,
Таң беленеп кояш торгач та.
Авыл әле бераз йоклап ала
Мал-туарын чыгып кугач та.
(“Авыл таңы”)


Күзем алмыйм иген
кырларыннан,
Башак шавы назлый колакны.
Үзем белән алып китәр идем
Һәр агачны, һәрбер куакны.
( “Туган җирем”)

# Сәхнә миңа илһам көче бирә.



*Институтта театр коллективы*
*җитәкчесе Мөбарәков М. С.*
1978 ел



*Әгерҗе халык театры. Ә. Атнабаев*
*"Ул кайтты"- Рәвия ролендә*
1982 ел



**Моңсу түгел миңа бер дә,**
**Гомер көземдә – язым.**
**Шатлыгымны бүлешергә**
**Янәшәмдә тиң ярым.**

# Рәхмәтле мин Сиңа, Әгерҗе!









“Мәрҗән” ансамбле белән



«Күңел чишмәләре» китабын тәкъдир
итү кичәсеннән соң
ноябрь 1998 ел



**Сокланмый түзәргә буламы,**
**Матур соң Әгерҗе яклары!**
**Җыр итеп җырлыйбыз Сине без,**
**Күңелнең җилкенгән чаклары.**

www.tvoyrebenok.ru

# “Күңел чишмәләре” әдәби-иҗат берләшмәсендә.



“Күңел чишмәләре” әдәби –иҗат берләшмәсенең киңәйтелгән утырышында галим, язучы Фоат Галимуллин белән
2000 ел


Сабантуйда халкым бәйрәм итә,
Уен көлке, җыр-моң агыла.
Ераклардан җирсеп дуслар кайта,
Туган-үскән газиз ягына. (“Сабан туе”)



Тукай белән үстек, балачактан
Шүрәлеләр белән көрәшеп.
Су буеннан алтын тарак тапкан
Авыл малаеннан көнләшеп.
(«Онытмыйбыз Тукайны.»)






Рушания апа! Бу очрашу күңелегездә матур хатирә булып саклансын.









**Күңел тирәнлеге төпсез дәрья сыман.**



## Дуслык җилкәннәре

Дуслык көчен җилкән итеп
Кузгалдык ерак юлга.
Яңа үрләрне яуларбыз
Тотынып кулны-кулга.
Бәйгеләрдә көч сынашып
Дуслашырбыз тагын да.
Киртәләрне тиз җиңәрбез
Бергә булган чагында.
Иж суының дулкыннары
Тибрәтте талгын гына.
Акчарлаклар шаһит булды
Ара якынлыгына.
Урман-күлләр кочагында
Назлы җилләр иркәләр.
Күңелләрдә тик бер теләк-
Тыныч булсын иртәләр.

# Файдаланылган әдәбият

Байтимерова Р.В. Гомер көземдә - язым: Шигырьләр.- Әгерҗе: 2012 – 96 бит: рәс. белән